СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №120 (7449) | 8 октябрь, 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

ДУСЛЫК

**Хөрмәтле укучылар!**

**Кабат исегезгә төшерәбез: «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасына язылу дәвам итә. Газетага үзвакытында язылып калырга киңәш итәбез. Аның еллык бәясе 78 сум.**

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ 1992 ЕЛДА ЧЫГАРЫЛГАН ХОСУСЫЙЛАШТЫРУ ЧЕКЛАРЫ СИСТЕМАСЫН ГАМӘЛГӘ КЕРТҮ ТУРЫНДА

# УКАЗЫ

Татарстан Республикасы гражданнарына дәүләт милкен тапшыруны тизләтү, халыкның киң катлауларын хосусыйлаштыру гамәленә тарту һәм Россия Федерациясенең бердәм икътисади киңлеген саклау максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә 1992 елда чыгарылган Россия Федерациясенең хосусыйлаштыру чекларын бирә башларга.

2. Татарстан Республикасының һәр гражданы 1992 елда чыгарылган номиналь бәясе 10 мең сум күләмендә булган бер хосусыйлаштыру чегы алырга хокуклы.

Татарстан Республикасы гражданнарына хосусыйлаштыру чеклары биргәндә 25 сум күләмендә комиссия җыемы алына.

1992 елда чыгарылган хосусыйлаштыру чеклары 1993 елның 1 гыйнвареннан 1993 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. 1992 елда чыгарылган хосусыйлаштыру чеклары турында Положениене расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

1992 елның 1 октябренә кадәр, гражданнарга хосусыйлаштыру чеклары биргәндә комиссия җыемы алу тәртибен расларга;

1992 елның 1 октябренә кадәр, Россия Федерациясенең хосусыйлаштыру чекларын кертү буенча территориаль комиссияләр оештырырга;

хосусыйлаштыру чекларын алырга хокуклы гражданнарның исемлеген төзүне тәэмин итәргә;

1992 елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча, 1992 елда чыгарылган хосусыйлаштыру чекларын Татарстан Республикасы гражданнарына бирә башларга.

5. Халыкка бирелгән хосусыйлаштыру чекларын үз вакытында акционерлык җәмгыятьләренең акцияләренә алмаштыру максатларында Татарстан Республикасының Милли инвестиция фондын төзергә.

6. Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитетына:

хосусыйлаштыру чекларын бирү һәм аларга түләү гамәленә методик җитәкчелек итүне тәэмин итәргә;

1992 елның 10 октябренә кадәр Министрлар Кабинеты раславына Татарстан Республикасының Милли инвестиция фонды турында Положениене эшләп кертергә:

хосусыйлаштыру чекларын туплый һәм Татарстан Республикасы территориясендә эшли торган махсус инвестиция фондлары турында Положение эшләргә һәм расларга.

7. Шәһәрләрнең, районнарның җирле администрацияләре башлыкларына хосусыйлаштыру чекларын тарату буенча үз өсләренә йөкләнгән вазифаларны башкару өчен саклык банкы бүлекчәләренә кирәк булган биналарны һәм җиһазларны бирергә һәм хосусыйлаштыру чеклары алырга хокукы булган гражданнарның исемлеген үз вакытында төзүне тәэмин итәргә.

8. Милекнең формасы нинди булуына бәйсез рәвештә, оешмаларга һәм предприятиеләргә товарлар һәм хезмәт күрсәткән өчен түләү сыйфатында хосусыйлаштыру чекларын кабул итү тыела.

9. Указ кул куелган вакытыннан көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. ШӘЙМИЕВ.**

**Казан, Кремль, 1992 елның 26 сентябре.**



Павел Петрович — авыл хезмәтенең күбесен тарткан, техниканың төрлесен иярләгән кеше. 30 елдан артык туган төбәгендә җир белән эш итә: сөрә, уңыш җыя, азык әзерли ул. Соңгы елларда Павел Петрович Т-70 тракторында эшли. Ул чөгендер игү звеносы члены. Җәйләрен азык әзерләүдә булды. Инде икенче урак җиткәч, иптәшләре белән татлы тамыр уңышын җыярга чыкты. Ул эшләгән 2 бригадада 75 гектарлы шикәр чөгендере һәм 15 гектарлы азык чөгендере мәйданында эш тиз тәгәлләнде. Аның кыска срокта тәмамлануында БМ-6 яфрак урдыру комбайнында эшләүче П. П. Волковның да өлеше күп керде. Павел Петрович һәр эштәге кебек монда да бик сыйфатлы, көйле эшләде.

Рәсемдә: «Ленинский путь» колхозы механизаторы П. П. Волков.

Л. Шәмсуаров фотосы.

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ЗАКОНЛЫЛЫГЫН ТӘЭМИН ИТҮНЕҢ ӨСТӘМӘ ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА

# УКАЗЫ

Хосусыйлаштыруның законлылыгын тәэмин итү, гражданнарның, хезмәт коллективларының мәнфәгатьләрен яклау, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә милекне дәүләт карамагыннан чыгару һәм хосусыйлаштыру барышында хокук бозуларны булдырмау һәм туктату максатында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасының Дәүләт милкен идарә итү буенча дәүләт комитеты каршында хосусыйлаштыруның законлылыгына контроль бүлекчәсе төзергә, аның эшчәнлегенә Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитеты һәм Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләрен тартырга.

2. Хезмәт урыныңдагы кешеләрне сатып алу һәм шантажлау, хезмәт урыныннан законсыз файдалану, фиктив яки ялган документлар бирү, мөлкәт сатып алганда җинаятьчел юл белән табылган түләү средстволарыннан файдалану фактлары ачылганда, шулай ук файдаланыла торган средстволарның законлылыгын раслый торган документлар булмаганда, хокук саклау органнары хосусыйлаштыру актларын законда билгеләнгән тәртиптә дөрес түгел дип тану буенча чаралар күрү өчен, материалларны Татарстан Республикасының Дәүләт милкен идарә итү буенча дәүләт комитетына тапшырырга тиеш.

3. Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгында, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең информация-белешмә системалары белән түләүсез хезмәттәшлек итү нигезендә икътисад һәм хосусыйлаштыру өлкәсендәге хокук бозулар турында мәгълүматларның ведомствоара автоматлаштырылган банкын булдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәге закон проектлары эшләргә: «Коррупциягә һәм финанс өлкәсендә законсыз эшләргә каршы көрәш турында Закон» — 1993 елның гыйнварендә, «Дәүләт хезмәте турында Закон» — 1992 елның декабрендә, «Хокук саклау органнары хезмәткәрләрен хокукый һәм социаль яклау турында Закон» — 1992 елның ноябрендә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу Указның үтәлешен тәэмин итә торган карарлар кабул итәргә.

6. Бу Указ кул куелу белән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. ШӘЙМИЕВ.**

**Казан, Кремль, 1992 елның 1 октябре.**

## Гражданнар игътибарына!

**Россия приватизация чеклары һәм исемле приватизация вкладлары системасын гамәлгә кертү буенча территориаль комиссия чеклар алу тәртибе турында мәгълүм Указлар уңаеннан, безгә түбәндәгеләрне хәбәр итте:**

— Татарстан президенты Указы нигезендә, Россия чеклары агымдагы елның 1 нче ноябреннән дә соңга калмыйча бирелә башлаячак. Хәзерге вакытта барлык авыл Советларында, шәһәрдәге торак-коммуналь хуҗалыклар, идарәләрдә гражданнарның тулы, дөрес исемлеге төзелә, бу хакта торак урыннарда белдерүләр эленде инде. Шуңа күрә дә коммуналь квартираларда яшәүчеләргә паспортлары, балигъ булмаган гаилә члennарының туу турында таныклыклары белән 11 октябрьгә кадәр үзләре теркәлгән торак-коммуналь хуҗалыкларга барырга, исемлеккә язылырга кирәк. Тору урыны буенча теркәлмәгән кешеләр шулай ук торак-коммуналь идарәләргә барып, аерым исемлеккә язылырга тиешләр.

Шәһәрдә шәхси йортлары белән яшәүчеләр өчен бу кагыйдә бераз үзгәрәк. Шәһәр Советы каршында махсус комиссия төзеләчәк, аннан җаваплы кеше билгеләнәчәк, ана бу хакта таныклык тапшырылачак (гражданнарга ачы күрсәтүен сорарга киңәш итәбез). Һәм ул һәр шәхси йортка кереп, йорт кенәгәсеннән, паспорт һәм туу турында таныклыклардан карап, үзе язып йөриячәк. Шәхси йортларда вакытлыча пропискасыз яшәүчеләр документлары нигезендә комиссия тарафыннан аерым исемлеккә теркәләчәк. Бу эш 8 октябрьдән 13 октябрьгә кадәр башкарылачак.

# КӨЗГЕ САБАН ТУЕНДА

(Репортаж)

## Мәйданда

Алдагы көннәрдә яңгыр явып күңелләргә шөбһә салса да, көзге сабантуй көне аяз килде. Әмма төньяктан искән әче җил, аэропортның ачык мәйданында үзен тиз сиздерде.

Ярминкә иртә таң атуга башланды. Райподан бирегә 20 дән артык сәүдә ноктасы чыккан иде. Алар белән янәшәдә эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре хезмәткәрләре, райпоның җәмәгать туклануы предприятиеләре буфетлары сәүдә итте.

Ләкин халык күбесенчә колхоз-совхозлардан килгән машиналар тирәсендә булды. Моны аңларга да була, арзан бәягә шәһәр халкы ит, ярма, яшелчә алып калырга ашыкты. Мөгезле эре терлек ите сата торган машиналар янында чиратлар пәйда булды.

Хуҗалыклар күп төрле ашамлык продуктлары алып килгәннәр иде. Ассортимент ягыннан «Рассвет» совхозыныкы иң мул булгандыр, мөгаен, дистәләгән төр яшелчә белән сәүдә итте. Бер очтан шуны да әйтү кирәк, ярминкәгә сәүдәне әйбәт һәм киң ассортиментлы оештырган өчен бу хуҗалык колхоз-совхозлар арасында оештырылган конкурста беренче урынны яулады. Икенче урынга Синдряков исемендәге колхоз, өченчегә «Большевик» чыкты.

Сабантуй, гадәттәгечә, ат чабышлары белән башланып китте. Ярышларда 30га якын чаптар катнашты. Чиста канлы чаптарлар арасындагы узышта да «Рассвет» совхозы атларын әйбәт хәзерләгән булып чыкты. Беренче төркем узышында хуҗалыкара берләшмәдән «Рубрика» беренче килде һәм бу токым атлар арасында иң югары нәтиҗә күрсәтте. «Камбуз» икенче, шул ук хуҗалыктан «Наговица» өченче булды.

Бу токым атлары өчен программага финал ярышлары да кертелгән иде. Ике әйләнешне иң шәп төгәлләгән чаптарлар кергән иде анда. Бу юлы бер әйләнештә көч сынашты атлар. «Рассвет»тан «Разбег» старттан ук беренчелекне кулга алды. Финишка җитәрәк аны «Наговица» куып җитте. Финиш сызыгын бер чама уздылар. Җиңү «Разбег»ка бирелде.

Җирле токым атлары ике зур төркемгә бүленеп чаптылар. Алар арасында җәйге сабан туенда да җиңгән «1 нче Май» аты «Сынок» җиңүче булды. «Рассвет»ның «Чайка»сы икенче, 21 партсъезд исемендәге колхоздан «Кашка» өченче призлы урынга чыктылар.

Юртаклар арасында да узыш берничә төркемгә бүлеп үткәрелде. Җиңүче вакыт буенча билгеләнде. Анда «1 май» колхозыннан «Плексия» кушаматлы ат беренче булды. «Рассвет»тан «Резерв» икенче, «Большевик»тан «Приказ» өченче нәтиҗә күрсәтте.

Салкын тамашачыларның канына тоз салса да, төрле уеннар үткәрелә торган мәйданга халык шактый җыелды. Күңел ачарга теләүчеләр: ир-ат, хатын-кызлар, мәктәптә укучы яшьләр дә төрле-төрле бәйгеләрдә көч сынаштылар.

Күз бәйләп чүлмәк вату да программага кертелгән иде. Ул уенның шарты үзгәртелде, чүлмәк урынына тупка сугу белән алмаштырылды. Бу төр ярышта Колбай Морасадан Айнур Әрдәширова осталык күрсәтте.

Аркан тарту балалар һәм өлкәннәр арасында да кызыклы узды. Бөҗра эченнән капчык белән сугып чыгару да физик хәзерлекле булуны таләп итә иде, көчлеләр алга чыкты. Көянтә белән су ташуда ир-атлар иң алдан узышты. Уенчыклар кисү, йөгерү буенча ярышларда укучылар бүләкләрнең төп өлешен яулады. Сөт (лимонад) имүчеләр конкурсы тамашачыларны елмаерга мәҗбүр итте.

Шома колга очына элеп куелган этәчкә күз атучылар шактый иде, билгеле. Тик һәркем аны алырга колга башына менеп җитә алмады. Бүләк РСУдан Алсым Шәкүровка эләкте.

Мәдәният работниклары да махсус программа әзерләгән иде. Сабантуй барышында төрле телдә җыр, музыка яңгырады. Анда авыл һәм шәһәр үзешчәннәре дә катнашты.

Милли көрәш 80 килограммга кадәр авырлыктагы ир-атларның бил алышуы белән башланды. Бу үлчәү категориясендә финалда Фомадан Җәмил Хәйруллин һәм Югары Норлаттан Фәрит Шәйхетдинов өченче урын өчен көрәштеләр. Аңа, көндәшен егып, Шәйхетдинов лаек булды. Чемпион исемен исә милиция хезмәткәре Әнәс Нәбиуллин һәм «Коопзаготпром» эшчесе Хәлим Шәрипов дәгъваладылар. Тәҗрибәле көрәшче Шәрипов үзенең көчлерәк икәнен янә раслады.

80 килограммнан артык авырлыктагы көрәшчеләр арасында чемпион исемен һөнәр училищесыннан Фаил Гайнуллин яулады, суыткычка лаек булды. Аның көндәше Фаик Хаҗиморатовка келәм эләкте.

Ике үлчәү категориясендә чемпион исемен яулаган Шәрипов һәм Гайнуллин сабан туеның абсолют батыры исемен алу өчен янә мәйданга чыктылар. Хафизов исемендәге колхоз бүләге — тәкә Гайнуллинга тапшырылды.

Көзге сабан туе бәйрәм рухында үтте.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.





Сабан туе күренешләре. Н. Азизов фотолары.

## Стадионда

Аэропортта сабан туе барган бер моментта спорт сөючеләр шәһәр стадионына җыелган иде. Анда районның футбол кубогын яулау өчен көрәшнең йомгаклау этабы узды.

Хәер, кубок өчен көрәш сентябрь башында ук башланган иде. Аңа 8 команда дәгъва итте. Финалга кадәр җиңү һәр команданың ике — үз һәм чит кырда үткәргән очрашулары буенча ачыклан ды.

«Россия» колхозы командасы МСО футболчыларын, НУРБ спортчылары Синдряков исемендәге колхоз егетләрен отып ярымфиналга чыктылар. Аларга НГДУ вәкилләрен җиңгән Спартак һәм «40 лет Победы» колхозыннан өстен чыккан Кузнецов исемендәге колхоз футболчылары да кушылды.

Ярымфиналда көрәш шактый кискен барды. НУРБ уенчылары «Россия» командасын отып финалга үттеләр. Аның көндәше шикәр заводының «Спартагы» булып чыкты. Ул моңа Кузнецов исемендәге колхоз коллективын җиңү нәтиҗәсендә иреште.

Һәм, ниһаять, сабан туе көнендә финал очрашуы үтте. Ул гаять киеренке көрәш шартларында барды. Билгеле ки, һәр команда кубок иясе булу өчен бар көчен, тырышлыгын куйды.


Беренче таймда инициатива нефтьчеләр кулында булды. Алар көндәшләре зонасында еш булдылар, тик исәпне генә ача алмадылар.

Икенче таймда яклар өзлексез бер-берсенең капкасын штурмладылар. Тайм уртасында чираттагы бер контратака вакытында спартаклылар исәпне ачтылар. Моның НУРБ спортчыларына мораль йогынтысы зур булды: алар һөҗүмгә күчтеләр, исәпне тигезләп кенә калмадылар, алга да чыктылар. Ул моментта очрашу тәмамланыр вакыт якынлашып килә иде, нефтьчеләр кубокны үзләренеке санадылар, тынычланып калдылар. Каршы як моны сизеп аларны «җәзаладылар», тагын бер туп кертеп нәтиҗәне тигезләде, 2:2 итте.

15 әр минутлык ике өстәмә тайм билгеләргә, ярышны яңабаштан башларга туры килде. НУРБ спортчылары бу юлы беренче минутларда ук алга чыктылар. Аннары икенче туп та кертүгә ирештеләр. Тайм тәмамланганчы яклар тагын берәр туп алмаштылар.

Шулай НУРБ командасы 5:3 исәбе белән бу очрашуны төгәлләп кубокны яулады.

Х. ФАТУЧЕВ.





## Музей ачылды

Билгеле булганча, Ватан сугышы каһарманы Александр Матросовның биографиясе, бигрәк тә балачагы ачык түгел. Аның Уфада балалар йортында тәрбияләнүе генә билгеле. Уфа журналистлары, ниһаять, Матросовның тормыш юлын ачыклауда зур эш башкардылар. Рәүф Насыйров һәм башка журналистларның ачыклавы буенча, Матросов Учалы районының Кунакбай дигән татар авылы егете Мөхәммәтҗанов Шакирҗан Юныс улы булып чыга. Шакирҗан бик кечкенәдән, төрле сәбәпләр аркасында, Газнави дигән малай белән авылдан чыгып китә, сукбайлар арасына эләгә, аны Саша дип йөртәләр. Тәрбиягә алынгач, Шакирҗан үзен Александр, фамилиясен Матросов дип яздыра. Чөнки кечкенәдән үк матрос булырга хыялланган була. Шакирҗан сугыш алдыннан авылына кайтып китә, үзен Саша дип атый. Урысча гына сөйләшә, матрос телняшкасы кигән була. Геройны аның авылдашлары, замандашлары фотосыннан таныйлар. Шакирҗан белән авылдан бергә чыгып киткән дусты Газнави да балачак дустын таный. Газнави үзе дә урыс булып язылган, хәзерге исеме Григорий. Геройның туган авылы Кунакбайда А.Матросов музее ачылды, анда Матросовның татар егете булуын раслаучы рәсми документлар, замандашларының истәлекләре бар.

## Газеталар берләшә

Чаллыдагы ике шәһәр газетасы — «Челны» һәм «Челнинская газета» лары берләшеп «Челнинская известия» дигән исем белән чыга башлады. Аның оештыручылары — халык депутатларының шәһәр Советы, шәһәр мэриясе һәм редакция коллективы.

Редакция коллективы, укучыларга мөрәҗәгать итеп, шәһәр тормышын киңрәк, проблемаларны хәл итүдә депутатлар һәм шәһәр хакимияте эшчәнлеген тулырак яктыртырга ышандыра. Укучыларны газета эшендә активрак катнашырга чакыра.

Х. МӨХӘММӘТШИН.

